**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге**
**Советы**

422743, Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авылы,
Совет урамы, 17а
тел. 3-34-05, факс 3-34-03

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Нижнеберескинского сельского поселения**

422743, Атнинский муниципальный район
с.Нижняя Береске,
ул. Совета, 17а
тел. 3-34-05, факс 3-34-03

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«05» ноябрь 2019 ел

№ 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елның 16 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

- гражданнар җыенын беренче этапта үткәрү вакытын 16 ноябрь 2019 ел 18.00 сәг.тән 19.00 сәг.кадәр билгеләргә:
- үткәрү урыны — Түбән Бәрәскә авылы, Чишмәле урамы, 21 нче йорт Бәрәскә мәдәният йортында – Чишмәле урамы №1 - №75 нче йортлар;Яңа урам №1 дән №45нче йортлар; Яшеллек урамы №1 -№16нчы йортлар;Тынычлык урамы №1-№30нчы йортлар;Татарстан урамы №1-№15 нче йортларда яшәүчеләр белән үткәрелә.

2. - гражданнар җыенын икенче этапта үткәрү вакытын 23 ноябрь 2019 ел 18.00 сәг.тән 19.00 сәг.кадәр билгеләргә:
- үткәрү урыны — Түбән Бәрәскә авылы, Чишмәле урамы, 21 нче йорт Бәрәскә мәдәният йортында – Ленин урамы №1 - №60 нчы йортлар;Үзәк урам №1 дән №17 нче йортлар; Совет урамы №1- №62 нче йортлар;Культуралы урамы №1-№14 нче йортлар;Тукай урамы №1-№12 нче йортлар; Казаклар урамы №1 -№15 нче йортларда яшәүчеләр белән үткәрелә.

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 10 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл жирлеге Башкарма комитетында гражданнар жыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Түбән Бәрәскә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар жыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Олы Өшкәтә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмәт чараларында гражданнар жыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Түбән Бәрәскә авыл жирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның жирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

1.- Түбән Бәрәскә авыл территориясен чистарту һәм төзекләндерү, агачларны кистерү һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- күперне төзекләндерү, төзелеш кирәк-ярагын алу һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2. Зиаратны төзекләндерү һәм карап тору өчен чыгымнар тоту;

3. Парк әйләнәсен чистартып тору очен чыгымнар тоту һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

4. Урам утларын карап тоту, лампочкалар алу өчен чыгымнар тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмәт рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Бәрәскә авылы, Совет ур., 17а йорт, Олы Өшкәтә авылы, Зур ур.15а йорт, Олы Бәрәзә авылы Зур ур.37а йортлардагы мәгълүмәт стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карар, ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.В.Фатыйхова